Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш гомуми урта белем бирү мәктәбе

Сыйныф сәгате

Тема:

“ Батырлар даны мәңгелек!”

Төзеде: Иске Үтәмеш гомуми урта белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы Мингулова Фәридә Имамутдин кызы.

2015 ел

МАКСАТ:

Балаларда Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннарга карата хөрмәт хисләре тәрбияләү, сугышның аянычлы нәтиҗәләре турында аңлату, балаларның үзләрендә патриотизм хисләре тәрбияләү,өлкән буын кешеләренә карата мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү,авылыбыз өчен горурлану хисләре уяту.

“Батырларның даны мәңгелек!” дип аталган сыйныф сәгатендә балаларга Бөек Ватан сугышында катнашкан авылыбыз ветераннары турында мәгълүмат бирү төп максатларның берсе булып тора.Шул ветераннар арасында күп укучыларның бабалары, туганнары бар.Ватан азатлыгы өчен яу кырларында газиз башларын салган якташларыбыз батырлыгы күпләргә үрнәк.

1941 елның 22 июне һәм 1945 елның 9 мае. Шушы ике көн арасында Ватаныбыз тарихының аерым бер олы сәхифәсе ята. Ул – совет халкының Бөек Ватан сугышында фашистлар Германиясенә һәм аның союздашларына каршы 1418 көн һәм төн буена фидакарь көрәше сәхифәсе.

Бу дөнья тарихындагы иң авыр сугыш була. Аның нәтиҗәсендә совет халкы миллионнарча корбаннар исәбенә үз Ватанының иминлеген, бәйсезлеген саклап кала, дөнья цивилизациясен коткаруга хәлиткеч өлеш кертә.

Татар халкы үзенең хәрби эшлеклеләре белән горурлана ала. Алар уртак Ватан өчен көрәштә, башка милләт вәкилләре белән иңгә-иң торып һәрвакыт каһарманнарча көрәшкәннәр. Дошман яуларына каршы аяусыз бәрелешләрдә татар генераллары һәм адмираллары үзләренең чын мәгънәсендәге полководецлык талантларын күрсәткәннәр. Әгәр“Татар барда хәтер бар”

дигән мәкалебезне дошман генераллары белгән булса, аларга моны фронтта шактый еш кабатлап торган булырлар иде. Үзләренең гомерләрен илебезнең бәйсезлеге өчен биргән бу каһарманнарны без бервакытта да онытмабыз. Алар даны мәңгелек!